**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА СТАРОАЛЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ӘЛМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

Иске Әлмәт
ав.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«05»ноябрь 2024 ел № 7

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Нариманов исемендәге поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 18 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка түбәндәге адрес буенча: Лесная урамында урнашкан мәчет янында Татарстан Республикасы, Нурлат муниципаль районы, Иске Әлмәт авыл җирлеге Нариманов исемендәге поселокта яшәүчеләр өчен үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлегендә халык җыены этапларын үткәрү һәм оештыру белән Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты тәэмин итә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге территориясендә яшәүче 1 гр инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм тол хатыннарыннан тыш һәр балигъ булган кешедән 1 000 сум, үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Нариманов ис. п. торак

пункты чикләрендә юлларны карап тоту, вак таш сатып алу, вак таш түшәү хезмәтләре күрсәтү, юлларны карап тоту, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Нариманов ис. п. торак пункты чикләрендә грейдерлау һәм алга таба вак таш салу өчен тыгызланган нигез салу хезмәтләре күрсәтү, шул исәптән сезонлы тоту);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Нариманов ис. п. торак пункты территориясен төзекләндерү);

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында района http://nurlat.tatarstan.ru, Иске Әлмәт авыл җирлегенең Иске Әлмәт авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хисамов